# Проектның темасы:

- ***Муса Җәлил** эзләре буйлап*

***Яр Чаллы шәһәренә сәяхәт.***

# Проектны эшләделәр:

50 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары :

- Мөбәрәкҗанова Л.Р.
- Низамиева Л.М.
- Шаһиева Ә.Ә.
- Ибраһимова З.Р.

Яр Чаллы, 2013 нче ел

# Проектның максаты:

***Шәһәребезнең истәлекле урыннарына сәяхәт аша Муса Җәлил иҗатын тирәнтен өйрәнү.***

## Бурычлар:

- Безнең төбәк тарихына, шагыйрьнең тормыш юлына һәм иҗатына карата балаларда кызыксыну уяту, мәхәббәт хисе тәрбияләү.
- Шагыйрь иҗаты буенча укучыларда танып-белү эшчәнлеген камилләштерү.
- Сәяхәт аша шагыйрьнең тормыш юлын күзаллауларын формалаштыру.

# Проектның концепциясе:

- Уку эшчәнлеген формалаштыру:
- Проект эшчәнлеге аша дәрестән тыш чараларда уку эшчәнлеген формалаштыру.
- Кызыксындырган сорауларга җавап таба белү, анализлау, мәгълүматны туплау һәм аны куллану.
- Куелган сорауларга җавап бирә белү, планлаштыру, төрле фикер-юнәлешләрен исәпкә алып, хезмәттәшлек итүгә омтылу.

# Планлаштырылган нәтиҗәләр:

- Уку эшчәнлегенә шәхси якын килү.
- Шагыйрь иҗаты буенча өстәмә мәгълүмат алу, туплау; үз туган төбәгебезнең истәлекле урыннарына игътибарлы булу.
- Әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә, мәдәниятебезгә багышлап үткәрелгән сәяхәт аша культуралы шәхес була алу.

# Регулятив уку эшчәнлеге:

- План буенча үз эшчәнлегеңне оештыра белү.
- Бирелгән рәсем - иллюстрацияләр ярдәмендә материалны күз алдына китереп, үз фикереңне әйтә белү.

# Танып-белү эшчәнлеген формалаштыру:

- Муса Җәлил исеме белән бәйле истәлекле урыннарны эзләү, барлау.
- Куелган бурычларны үтәгәндә, инициатива күрсәтү.

# Коммуникатив уку эшчәнлеге:

- Куелган бурычларны чишкәндә, укытучы - укучыларның үзара хезмәттәшлек итә белүе.
- Һәр катнашучының үз фикерен тыңлый белүләре аша диалогик сөйләмгә керү.
- Күмәк фикер алышуда катнашу.
- Сәяхәткә бәйле мәгълүматны күзәтеп,телдән үз фикереңне оештырып, башкаларга җиткерә алу.

# Шәхси универсаль уку эшчәнлеген формалаштыру:

- Күзәтү вакытында эмоциональ кичерешләрне белдерү.
- Башкаларның кичерешләрен аңлый белү.

Проектны тормышка ашыруда көтелгән нәтиҗәләр:

- Балалар шагыйребез иҗаты буенча тулырак белем алуга ирешәләр.
- Туган төбәгебезнең истәлекле урыннары турында төгәл мәгълүматлар алалар.
- Күргән материал аша үз фикерләрен формалаштыра һәм башкаларның фикерләрен аңлый алуга ирешәләр.
- Телдән үз фикерләрен оештыра белергә өйрәнәләр.


# Янып калсын гомрең маяк булып



- Муса Җәлил... Шагыйрь... Советлар Союзы Герое... Ленин премиясе лауреаты...
- Бу легендар исемне миллионнар белә.
- Муса Җәлил диюгә, татар халкын, ә татар халкы диюгә, Муса Җәлилне күз алдына китерәләр.



Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. 1913 елда Мусаның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә һәм вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә башлый.



Муса Җәлилнең туган авылы Мостафа







Шагыйрьнең
этисе
Мостафа ага
һәм әнисе
Рәхимә апа





# Муса Җәлилнең гаиләсе














# Мусаның уку еллары



Муса 6 яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында (1914—1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кулъязма журналга урнаштыра бара.

Муса Җәлил хатыны Әминә белән



Муса Җәлил кызы Чулпан белән






Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул үзен фронтка җибәрүләрен сорый.

алга 1

алга 2

# Сугыш еллары




1941 елның июль аенда М. Җәлил армиягә алына. Башта ул Казан гарнизоны хәрби частендә рядовой кызылармеец булып хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге политработниклар әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә фашист гаскәрләре якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. 1941 елның декабрендә курсларны тәмамлагач, өлкән политрук М. Җәлил Мәскәү аша фронтка китә.

Тоткынлыкта



1942 елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә.




791 көн әсирлектә



Җәлил яшерен оешмага 1943 нче елның башларыннан ук кушыла, фашизмга каршы төрле юллар белән эш алып бара, “Идел-Урал” комитетында эшли. Яшерен оешма әсирләрнең кораллы востаниесен әзерли, ләкин аны гестапо белә, һәм җәлилчеләр восстаниегә берничә көн кала кулга алыналар.



Исемнәре кайтты илгә җыр булып.

Җәлилчеләр палач алдында баш имәгән, горур булып калган. Хәтта үлемгә дә алар, надзиратель әйтүе буенча, башларын югары күтәреп, ниндидер татар җырын җырлап барганнар. Бу “азиатлар” ның батырлыгына палачлар да таң калган.



Тегель төрмәсе

1943 елның җәе



Шпандау төрмәсе

1944 ел, соңгы көннәр



Плетцензе төрмәсе

Җәзалау урыны

Җәлилчеләр 1944 елның 25 августында 12 сәг. 06 мин. тан 12 сәг. 36 мин. ка кадәр Берлиндагы Плетцензе төрмәсендә гильотинада җәзалап үтереләләр.



Изге уйлар, таудай теләкләр күп,

Сулыйсы иде Ватан һавасын!

Дәвам итеп мәңге, кылганнарыбыз


Бер матур җыр булып яңгырасын!



Беренче дәфтәрдә 60 шигырь,

икенче дәфтәрдә 50 шигырь тупланган.





алга

артка

Муса Җәлилгә 1956 нчы елны Советлар Союзы Герое исеме бирелә









Җәлил – шигырьләрдә, сәхнә әсәрләрендә, картиналарда... Шагыйрь сурәтеннән нинди дер тылсымлы балкыш бөркелә сыман. Бу балкыш безне һәрчак үзенә дәшә. Намуслы яшәргә, бернинди кыенлыклар алдында сынатмаска чакыра.





# Җəлил эзлəре буйлап Чаллы шəһəренə сəяхəт



# Муса Җәлил

Муса Җәлил проспекты

Муса Җәлил исемендәге китапханә

Шагыйрьнең һәйкәле

Муса Җәлил исеме белән бәйле чаралар



# 1979 нче елда Яр Чаллы шәһәрендә яңа проспект төзү башлана...










# Ул проспектка 1984 нче елда Муса Җәлил исеме бирелә.











# Яр Чаллының Муса Җәлил исемендәге үзәк китапханәсе.




- **Китапханә** 1976 нчы елның гыйнварында ачыла.
- **Китапханә** ГЭС бистәсендә урнашкан.
- **Китапханә**дә балалар өчен аерым бүлек эшли, анда 14 яшькә кадәр балалар йөри.

Китапханәдә балалар өчен бик күп әдәби чаралар, конкурслар, танылган кешеләр белән очрашулар, экскурсияләр үткәреләә.



# «Җәлил» мемориаль һәйкәле



# Һәйкәл турында...

- Җиңүнең 40 еллыгына 1985 нче елда ачыла.
- Үзәк урам белән Универсам тукталышлары арасында урнашкан.
- Һәйкәл таш плитәдән ясалган һәм Берлин төрмәсенең символы (тормышның мәңгелек булуын күрсәтә), ә Муса Җәлилнең бюсты кызыл граниттан эшләнгән.

# Һәйкәлнең скульпторы –Лидия Зимина



- Лидия Зимина 1933 нче елда Чиләбе өлкәсе Златоуст шәһәрендә туа.
- 1974 нче елда Чаллыга килә, 30 елдан артык шәһәребездә иҗат итә.
- Сарман, Мөслим, Минзәлә, Балтач, Яр Чаллы шәһәрләрендә күп кенә һәйкәлләрен күрергә була.

Ул үзе дә һәйкәлгә чәчәкләр салырга килә. Һәм үзенең бу скульптура әсәре турында бик горурланып сөйли.



# Һәйкәлнең архитекторы – Георгий Иванов



- 1946 нчы елда Казанда туа.
- 1971 нче елда Чаллы шәһәренә килә.
- КамАЗда баш архитектор булып эшли.
- Энергетик мәдәният сарае, Татарстан кунакханәсе, “Иске шәһәр” мемориаль зонасын эшләүдә үз өлешен кертә.

# Һәр елның 15 нче февралендә һәйкәл янында Муса Җәлилне искә алу кичәсе үткәрелә.




- Укучылар, танылган язучылар шагыйрьнең шигырьләрен укыйлар, ә җырчылар аның сүзләренә язылган җырларны башкаралар. Соңыннан һәйкәлгә чәчәкләр салу тантанасы була.

Һәр елның февраль аенда Яр Чаллы шәһәрендә Муса Җәлил призына татар – башкорт көрәше турниры уздырыла. Анда Республикабыз һәм Россиянең күп кенә төбәкләреннән 500 гә якын спортчы катнаша.









# Белемеңне тикшер



Тест №1

Тест №2

Тест №3

Тест төзү өчен сораулар

артка


М.Җәлил кайчан туган?

1902 елның 23 февралендә

1886 елның 26 апрелендә

1906 елның 15 февралендә

# Дөрес түгел



1 сорау

2 сорау

3 сорау

4 сорау

5 сорау

# М.Җәлил кайда туган?

Оренбург өлкәсе
Мостафа авылы

Казан шәһәре

Арча районы
Кушлавыч авылы

Чаллыда Муса Җәлилнең һәйкәле кайчан төзелгән?

1980

1985

1982

Муса Җәлил һәйкәленең скульпторы?

Бакый Урманче

Илдар Ханов

Лидия Зимина


Муса Җәлил исемендәге китапханә кайда урнашкан?

ГЭС бистәсендә

ЗЯБ бистәсендә

Яңа шәһәрдә

# Булдырдың!



артка

# Кулланылган әдәбият


- http://km.edu.tatar.ru/
- http://belem.ru
- http://www.tatknigafund.ru
- wwwwww.www.tatarwww.tatar.www.tatar.com.
- wwwwww.www.kitapwww.kitap.www.kitap.netwww.kitap.net.www.kitap.net.ru
- wwwwww.www.tatartelewww.tatartele.www.tatartele.ru
- wwwwww.www.kitapxanewww.kitapxane.www.kitapxane.ru
- www.tatarica.narod.ru
- Энциклопедия города Набережные Челны - Казань: Издательство «Идел-Пресс»,2007
- Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф,2004. – 271 б.
- Җәлил М. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан “Хәтер” нәшриятьы (ТаРИХ), 2004.- 575 б.